РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛКОМ БОЛЬШЕЧЕКМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ЧАКМАК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

*423993, РТ, Муслюмовский район. с. Большой Чекмак, ул. Центральная 1,*
*Bchak.Mus@tatar.ru тел. (8-85556) 3-10-97*
ИНН 1629003939, КПП 162901001, ОГРН 1061687005160, ОКАТО 92242816000

с.Большой Чекмак « 21 » марта 2019 г.

# КАРАР №6

**2019 елгы язгы ташу чорына Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге халкын һәм территориясен саклау чаралары турында**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 7 маддәсе нигезендә 2019 елгы язгы ташу чорында халыкны, хуҗалык һәм торак объектларын, юлларны һәм күперләрне саклауны кисәтү максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Олы Чакмак авыл җирлеге территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия төзү.
2. Олы Чакмак авыл җирлеге территориясендә 4 кешедән торган гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясен төзергә һәм 2019 елгы язгы ташу чорында Олы Чакмак авыл җирлеге халкын һәм территориясен саклау буенча чаралар планын расларга.
3. Олы Чакмак авыл җирлеге гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерүне һәм икътисад объектларының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә тәкъдим итәргә:
   - Олы Чакмак авыл җирлегенең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм янгын куркынычсызлыгы, язгы ташуга каршы комиссия утырышларында икътисад объектларының куркынычсызлыгы, язгы ташу суларының авариясез үтүен тәэмин итү мәсьәләләрен карарга;
   - язгы ташу күренешләре аркасында килеп чыккан гадәттән тыш хәлләргә игътибар бирү һәм авария-торгызу эшләрен үткәрүгә җәлеп ителә торган көч һәм чаралар группировкасын ачыклау. Көч һәм чаралар турында мәгълүматлар җыю һәм гомумиләштерү, аларның гамәлләрен тикшереп тору;
   - елга һәм буаларда, саркофагларсыз үләт базлары янында су дәрәҗәсен тәүлек буе күзәтү өчен вакытлыча постлар оештырырга; - язгы ташуга каршы чаралар оештыруны тәэмин итү;
   - язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен халыкка җиткерүне тәэмин итәргә;
   - халыкны һәм территорияләрне язгы ташуның тискәре нәтиҗәләреннән саклау буенча чараларның үткәрелүен контрольдә тотуны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Олы Чакмак авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.М.Габидуллин**

Мөслим муниципаль районы
Олы Чакмак авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесенең
«21» март, 2019 ел,
2нче санлы Карарына
1нче кушымта

**Олы Чакмак авыл җирлеге буенча**
**гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне тәэмин итү комиссиясе**

1. Габидуллин Ильнур Мухтарович
2. Шафигуллина Наиля Макаримовна
3. Шигапов Ильшат Исхакович
4. Шаймиев Ильдар Зуфарович

**Олы Чакмак авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.М.Габидуллин**